**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18 май 2026 ел № 543

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2023 елның 16 октябрендәге 1312 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2023 елның 16 октябрендәге 1312 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күрсәтелгән карар белән расланган опека, попечительлек (шул исәптән алдан опека һәм попечительлек) билгеләү, опекунны (попечительне) үз вазыйфаларын башкарудан азат итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.6.1 пунктның 7 пунктчасында "мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк" сүзләрен “мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин